| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>БАГАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БАГАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

27.12.2021 ел. Багай ав. № 20

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлеге Советының кайбер карарларын үз көчен югалткан дип тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә һәм муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлеге территориясендә җирләрдән файдалануга муниципаль җир контроле турында нигезләмә хакында» 2011 елның 13 декабря 10 номерлы карарын;

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлеге Советының «Багай авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышына муниципаль контроль турында нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 25 июнендәге 17 номерлы карарын.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кайбыч муниципаль районы Багай авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Багай авыл җирлеге Башлыгы Р.Ф.Кузнецова